РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» окябрь 2025 ел** **№ 6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 12 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 12 ноябрендә 10.00 сәгтән 11.00 сәг кә кадәр;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны – Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 50 й., Илбәк мәдәният йорты дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 28 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 10а адресы буенча урнашкан

мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Илбәк торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Илбәк торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда 1төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 350 (өч йөз илле) сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);
- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Ә.Вәлиев урамындагы 23нче йорттан алып - 27нче йортка; 41/2 нче йорттан алып – 47А йортына кадәр юлга вак таш сатып алу, төяү, ташу, тарату, юлны профильләштерү);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

РИЗА КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Р.К.Галимҗанова